ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 2012 елның 25 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«12 статья. **Гавами чаралар уздыру тыела торган урыннар**

Федераль законның 8 статьясының $2^2$ өлеше нигезендә, гавами чаралар уздыру кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен, законлылыкны, хокук тәртибен һәм җәмәгать иминлеген бозуга, шул исәптән яшәеш тәэмин итү, транспорт яисә социаль инфраструктура, элемтә объектлары эшчәнлеген бозуга китерсә, җәяүлеләрнең һәм (яисә) транспорт чараларының хәрәкәтенә йә гражданнарның торак урыннарына яисә транспорт яки социаль инфраструктура объектларына керә алуына тоткарлык тудырса, җыелышларны, митингларны, урам йөрешләрен, демонстрацияләрне түбәндәге урыннарда уздыру тыела:

1) яшәеш тәэмин итү объектлары, хәрби объектлар янәшәсендәге территорияләрдә, шулай ук «Террорчылыкка каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә халыкның террорчылыктан саклануын

тәэмин итү максатында күпләп җыелу урыннарына карый торган биналар янәшәсендәге территорияләрдә;

2) тимер юл вокзаллары һәм платформалары, автобус һәм елга вокзаллары, аэропортлар, метрополитен, элемтә объектлары, маршрут транспорт чаралары тукталышлары янәшәсендәге территорияләрдә;

3) мәгариф, медицина, физкультура-савыктыру, спорт оешмалары, социаль хезмәт күрсәтү, мәдәният, балаларның һәм яшьләрнең ял итү оешмалары, гыйбадәтханә корылмалары янәшәсендәге территорияләрдә;

4) транспорт чараларын кую урыннары (парковкалар) территорияләрендә;

5) балигъ булмаганнар һәм инвалидлар ялы өчен каралган һәм җиһазландырылган территорияләрдә.

Кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре, законлылык, хокук тәртибе, җәмәгать иминлеге бозылу, шул исәптән яшәеш тәэмин итү, транспорт яисә социаль инфраструктура, элемтә объектлары эшчәнлеге бозылу куркынычын бәяләү, җәяүлеләрнең һәм (яисә) транспорт чараларының хәрәкәтенә йә гражданнарның торак урыннарга яисә транспорт яки социаль инфраструктура объектларына керә алуына тоткарлык тууны бәяләү, конкрет гавами чараның үзенчәлеген исәпкә алып, аның максатлары һәм төреннән (характерыннан), анда катнашучыларның фаразланган санынннан, уздыру датасыннан, башлану һәм тәгәлләнү вакытыннан, уздыру урыныннан, шулай ук башка билгеләреннән чыгып, вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 25 декабрь
№ 111-ТРЗ